**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«19» 11 2025 ел Яр Чаллы ш. № 3829

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Лебедушка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифныраслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Лебедушка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Лебедушка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Муниципаль район Башкарма комитетының 2025 елның «19» 11. 3829 номерлы карарына 1 кушымта

2025 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Лебедушка» балалар бакчасы буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Тылсымлы пластилин» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Считалочка» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Уен ритмикасы» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

2026 елның 1 январеннан

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Тылсымлы пластилин» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Считалочка» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Уен ритмикасы» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Лебедушка» балалар бакчасы мөдире ________ Л.Р. Шакирова

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары ________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Лебедушка» балалар бакчасы тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Тылсымлы пластилин»** - традицион булмаган пластилин белән эшләү техникасын үзләштерү аша кулларның вак моторикасын үстерүгә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 48,7 кв.м, балалар саны - 12.

Дәресләр атнага бер тапкыр үткәрелә.

2. **«Бер баскыч, ике баскыч»** - математика, логик фикерләү, танып белү активлыгы һәм математик сәләтләр белән кызыксынуны үстерүгә юнәлдерелгән.

Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 48,7 кв.м, балалар саны - 10.

Дәресләр атнага бер тапкыр үткәрелә.

3. **«Уен ритмикасы»** - программа балаларның музыкаль һәм иҗади сәләтләрен формалаштыруга юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 63,0 кв.м, балалар саны - 13.

Дәресләр атнага бер тапкыр үткәрелә.

ТР Тукай муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем
бирү учреждениесе - «Лебедушка»
балалар бакчасы мөдире Л.Р. Шакирова